ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2025 п.г.т.Алексеевское № 538

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының спорт ветераннары Советын төзү турында**

Урта, өлкән һәм өлкән яшьтәге затлар арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, спорт хәрәкәтен камилләштерү һәм үстерү максатында

**карар бирәм:**

1. Спорт ветераннары Советын төзергә һәм аның составын расларга (1 нче кушымта).
2. Спорт ветераннары Советы турындагы нигезләмәне (2 нче кушымта) расларга.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеген спорт ветераннары Советы эшчәнлеге координаторы итеп билгеләргә.
4. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында һәм Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**Җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_08.12.2025 ел,_ №_538_
карарына 1 нче кушымта

**Спорт ветераннары Советы**
**Составы**

| | |
|---|---|
| Макарихина Елена Степановна | Спорт ветераннары Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы ветераннар (пенсионерлар) оешмасы советы рәисе (килештерү буенча) |
| Кәбиров Рөстәм Рәшитович | Спорт ветераннары Советы рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Спорт мәктәбе» ӨББ МБУ директоры |
| Крылова Анна Ивановна | Спорт ветераннары Советы секретаре (килештерү буенча) |
| Комиссия әгъзалары:<br>Гыймадиев Фәршат Шәмсетдинович | Спорт ветераны, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Спорт мәктәбе» ӨББ МБУ Биләр авылы спорт комплексы мөдире |
| Сөләйманов Бари Равильевич | Спорт ветераны, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Спорт мәктәбе» ӨББ МБУ тренер-укытучысы |
| Малафеев Борис Андреевич | Спорт ветераны, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Спорт мәктәбе» ӨББ МБУ тренер-укытучысы |
| Никешин Владимир Викторович | Спорт ветераны, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Спорт мәктәбе» ӨББ МБУ тренер-укытучысы |
| Типясев Геннадий Иванович | Спорт ветераны, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Спорт мәктәбе» ӨББ МБУ тренер-укытучысы |
| Белов Алексей | Спорт ветераны, Татарстан Республикасы Алексеевск |

| | |
|---|---|
| Михайлович | муниципаль районының «Спорт мәктәбе» ӨББ МБУ тренер-укытучысы |

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_08.12.2025 ел,_ №_538_
карарына 2 нче кушымта

**Спорт ветераннары Советы турында**
**Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Спорт ветераннары Советы (алга таба – Совет) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән районда урта, өлкән һәм өлкән яшьтәге затлар (алга таба – спорт ветераннары) арасында спорт хәрәкәтен популярлаштыру, камилләштерү һәм үстерү өчен төзелгән консультатив орган булып тора.

1.2. Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына, муниципаль хокукый актларга һәм әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.3. Совет үз эшчәнлеген физик культура, спорт, сәламәтлек һәм озын гомер мәсьәләләре булган спорт учреждениеләре һәм башка оешмалар белән берлектә гамәлгә ашыра.

## 2. Советның максат һәм бурычлары

2.1. Эш максатлары:

- спорт ветераннарының актив тормыш позициясенә ярдәм итү;
- спорт ветераннары белән спорт-савыктыру эшен оештыру системасын үстерү;
- ветераннар хәрәкәтен үстерүгә ярдәм итү, сәламәт яшәү рәвешен һәм спортта озак яшәүне пропагандалау, спорт белән шөгыльләнүгә күбрәк кешене җәлеп итү.

2.2. Советның төп бурычлары булып тора:

1) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә җирле үзидарә органнарының җәмәгать физкультура-спорт оешмалары һәм мәгариф, спорт учреждениеләре, шулай ук физик культура һәм массакүләм спорт өлкәсендә башка кызыксынган затлар белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;

2) урта, өлкән һәм өлкән яшьтәге затлар арасында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүне пропагандалауга ярдәм итү, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының спорт ветераннары хәрәкәтен массакүләм мәгълүмат чараларында популярлаштыру;

3) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә ветераннар хәрәкәтенең физик культурасын һәм спортын үстерү буенча перспективалы сәясәтне формалаштыруда катнашу;

4) спорт ветераннары арасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын популярлаштыру һәм үстерү;

5) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы ветераннар хәрәкәтенең физик культураны һәм спортны үстерүгә бәйле актуаль проблемаларны ачыклау, гомумиләштерү, анализлау;

6) җирле үзидарә органнары, спорт федерацияләре һәм башка физкультура-спорт оешмалары һәм берләшмәләре эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү.

2.3. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән төп бурычларны гамәлгә ашыру өчен Совет түбәндәге функцияләрне башкара:

1) тәкъдимнәр эшли:

а) ветераннар хәрәкәтенең физик культура һәм спорт өлкәсендә муниципаль программаларны әзерләү һәм гамәлгә ашыру буенча;

б) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының ветераннар хәрәкәтенең физик культурасын һәм спортны үстерү өлкәсендәге эшен камилләштерү буенча;

в) спортчы-ветераннарны әзерләү буенча;

г) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә физик культураны һәм спортны, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау чараларын үткәрү буенча;

д) ветеран спортчылар өчен физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен матди-техник базаны үстерү буенча;

е) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә физик культураны һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә юнәлдерелгән башка мәсьәләләр буенча;

2) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү эше торышы турында мәгълүмат җыя һәм анализлый;

3) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Ветераны спорта» битен эшләү;

4) ветераннар хәрәкәте тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм яшь буынга тапшыру (спорт ветераннары һәм спорт мәктәпләрендә укучылар белән очрашулар);

5) Совет бурычларына туры килә торган башка функцияләр.

## 3. Советның структурасы һәм эшчәнлек тәртибе

3.1. Советның шәхси һәм сан составы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

3.2. Совет җирле үзидарә органнары, муниципаль учреждениеләр вәкилләреннән, спорт ветераннарыннан кимендә 9 кешедән төзелә.

3.3. Совет составына рәис, рәис урынбасары, секретарь, Совет әгъзалары керә.

3.3.1. Совет Рәисе:

1) Советны җитәкли һәм Совет эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

2) Советның эш планнарын Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге башлыгы белән килештерә;

3) Совет утырышларының көн тәртибен раслый;

4) Совет утырышын алып бара;

5) Совет утырышлары беркетмәләренә имза сала;

6) Совет әгъзаларының тавышлары тигез булган очракта хәлиткеч тавыш хокукына ия.

Совет рәисе булмаганда аның вәкаләтләрен Совет рәисе урынбасары башкара.

3.3.2. Рәис урынбасары:

1) Совет утырышларын әзерләгәндә оештыру мәсьәләләрен хәл итүне тәэмин итә;

2) Совет утырышында карау өчен материал һәм документлар әзерли;

3) бер айга Советның эш планын төзи һәм аны Совет утырышларында тәкъдим итә.

3.3.3. Совет Секретаре:

1) Совет утырышлары беркетмәсен алып бара;

2) Совет компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча Совет рәисе һәм рәис урынбасары йөкләмәләрен үти;

3) Совет әгъзаларына Совет утырышын үткәрү көн тәртибе, датасы, урыны һәм вакыты турында үз вакытында хәбәр итә.

3.4. Совет үз эшчәнлеген расланган эш планы нигезендә утырышлар уздыру юлы белән гамәлгә ашыра.

3.5. Совет утырышлары кирәк булган саен, кварталга бер тапкырдан да сирәгрәк уздырылмый.

3.6. Әгәр Совет утырышларында составның яртысыннан артыгы катнашса, ул тулы хокуклы.

3.7. Совет әгъзалары кирәкле санда булмаган очракта, Совет утырышы күчерелә.

3.8. Совет карарлары утырышта катнашучылар саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, Совет рәисенең тавышы хәлиткеч була.

3.9. Совет карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул Совет рәисе һәм Секретаре тарафыннан имзалана.

3.10. Үз эшчәнлеген гамәлгә ашырганда Совет хокуклы:

1) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге башлыгына Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә ветераннар хәрәкәтенең физик культурасын һәм спортын үстерү һәм камилләштерү мәсьәләләре буенча рекомендация, тәкъдимнәр кертергә;

2) Совет компетенциясе кысаларында дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан физик культура һәм спорт мәсьәләләре буенча мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

3) Совет утырышларына дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешмалар вәкилләрен, спорт җәмәгатьчелеген чакырырга;

4) җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешмалар белән уртак чаралар оештырырга, шул исәптән Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә физик культураны һәм спортны үстерү һәм популярлаштыру мәсьәләләре буенча фикер алышу өчен;

5) Совет компетенциясе кысаларында башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

## 4. Йомгаклау нигезләмәләре

4.1. Совет карарлары рекомендация характерында.

4.2. Совет карарлары Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге башлыгына, ә кирәк булганда, башка вазыйфаи зат һәм оешмаларга рәис һәм секретарь имзалаганнан соң 5 эш көне эчендә җибәрелә.

4.3. Совет эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

**Башкарма комитетының**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**